ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
12.02.2025

**К А Р А Р**
№ 202

**«Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре», «Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» конкурсын уздыру турында**

Югары квалификацияле кадрларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү, алар үрнәгендә яшь белгечләрне тәрбияләү, сәламәтлек саклау хезмәткәрләре һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 13 февраленнән 2025 елның 25 февраленә кадәр «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре», «Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» конкурсын үткәрергә.

2. Расларга:

- «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре», «Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» конкурсы турында нигезләмәне (1 нче кушымта);
- Конкурс комиссиясе составын (2 нче кушымта).

3. Эш комиссиясенә конкурска йомгакларны 2025 елның 27 февраленә кадәр ясарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның12 феврале номерлы
карарына
1 нче кушымта

**«Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре», «Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» конкурсы турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Конкурсның максатлары

Сәламәтлек саклау белгечләре өчен һөнәри камилләштерүгә, нәтиҗәле хезмәткә, аны рациональ оештыруга өстәмә стимуллар булдыру.

Медицина хезмәткәренең престижын, абруен, иҗтимагый әһәмиятен күтәрү.

2. Конкурсның бурычлары

Медицина персоналы, шулай ук оешманың башка персоналының төрле категорияләре буенча иң квалификацияле белгечләрен ачыклау.

Җиңүчеләрне югары һөнәри осталык һәм эшне нәтиҗәле оештырган өчен бүләкләү.

Тармакта, Биектау районы халкы арасында иң яхшы белгечләрнең казанышларын, аларның алдынгы тәҗрибәләрен пропагандалау, реаль кыенлыкка, җаваплылыкка һәм аның хезмәтенең әһәмиятенә җавап биргән медицина хезмәткәре имиджын формалаштыру.

3. Материалларны тапшыру һәм рәсмиләштерү тәртибе

3.1 Әлеге тәртип документларны рәсмиләштерүгә һәм конкурсның төп этапларын уздыруга карата таләпләрне билгели. Катнашучыларның барлык документлары конкурс комиссиясе тарафыннан 2025 елның 28 февраленә кадәр кабул ителә.

Конкурста «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУнең медицина һәм башка хезмәткәрләре катнаша ала.

3.2 Конкурс номинацияләре:

«Елның иң яхшы табибы»;

«Иң яхшы урта медицина хезмәткәре»;

«Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр».

3.3 Конкурсантларны тәкъдим итү.

Конкурска тәкъдим итү «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ коллективы тарафыннан башкарыла.

«Иң яхшы табиб» номинациясендә катнашуга барлык белгечлекләр табибларына рөхсәт ителә. Җиңүчене билгеләгәндә бәяләү критерийлары булып торалар:

-2024 ел дәвамында конкурсант эшчәнлеге статистик күрсәткечләренең уңай динамикасы;

- 2024 ел дәвамында авыруларны алып баруның медицина стандартларын бозу очраклары булмау;

- 2024 ел дәвамында табибның гамәлләренә, шул исәптән табиб этикасын бозуга бәйле шикаятьләрнең булмавы;

- «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ үсешенә керткщн шәхси өлеше;

- мәгълүмат ресурсларына ия булуы;

- башкару дисциплинасы һәм дисциплинар җаваплылык.

«Иң яхшы урта медицина хезмәткәре» номинациясендә катнашуга «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУнең урта һөнәри белемле һәм квалификация категориясе булган медицина хезмәткәрләре кертелә. Җиңүчене билгеләгәндә бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

- ел дәвамында нигезле шикаятьләре булмау;
- «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ үсешенә керткән шәхси өлеше;
- мәгълүмат ресурсларына ия булуы;
- башкару дисциплинасы һәм дисциплинар җаваплылык.

«Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» номинациясендә катнашуга «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ үсешенә, һөнәргә, сәламәтлек саклау системасына өлеш керткән медицина белеме булмаган хезмәткәрләр тәкъдим ителә. Җиңүчене билгеләгәндә бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

- ел дәвамында нигезле шикаятьләр булмавы;

- «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ үсешенә шәхси өлеш кертүе;

- башкару дисциплинасы һәм дисциплинар җаваплылык.

## 4. Конкурс этаплары

4.1. Конкурсның беренче сайлап алу этабы «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУдә уздырыла. Һәр номинациядә өчәр кандидат сайлана. Һәрбер кандидатура «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУнең баш табибы боерыгы белән расланган комиссия тарафыннан карала. Беренче этапта җиңүче һәм призерлар турында карар ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителә һәм әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә гомуми җыелыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Беркетмәдә чагылыш табарга тиеш: хезмәткәрнең әхлакый сыйфатлары – мәрхәмәтлелеге, ихлас күңеллелеге, кызгану сәләте, авыруның шикаятьләрен игътибар белән тыңлавы, үз киңәшләреңнең мәгънәсен аңлата белүе, зарарлы гадәтләрдән баш тартырга күндерә белүе, экстремаль ситуацияләрдә үз-үзен тотышы, эш вакытыннан тыш эшләүгә мөнәсәбәте кебек аспектлар;

статистик күрсәткечләр динамикасын чагылдырып, һөнәри эшчәнлегенең төп йомгаклары турында белешмәләр;

учреждение үсешенә керткән шәхси өлеше турында белешмәләр;

мәгълүмат ресурсларына ия булуы турында белешмәләр;
оешма коллективы һәм аның җитәкчесе фикере;
арадаш һөнәрләргә ия булуы турында белешмәләр;
башкару дисциплинасын үтәве һәм дисциплинар җәзаларның булуы/булмавы турында мәгълүмат.

4.2. Конкурсның икенче этабы Биектау районы администрациясе белән берлектә уза. Икенче этапны уздыру барышында әлеге карар белән расланган Комиссия конкурска җибәрелгән материалларны бәяләү критерийлары нигезендә эксперт бәясен гамәлгә ашыра һәм җиңүчене билгели. Комиссия тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән конкурс номинантларының берсен сайлана. Карар аның өчен күпчелек тавыш биргән очракта кабул ителгән дип санала. Конкурста җиңүчеләргә сертификатлар тапшырыла:
«Елның иң яхшы табибы» 50 000 (илле мең) сум;
«Иң яхшы урта медицина хезмәткәре» 30 000 (утыз мең) сум;
«Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» 20 000 (егерме мең) сум.

Конкурс номинантлары турындагы карар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Номинантлар турында мәгълүмат мәҗбүри рәвештә «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУнең рәсми сайтында бастырыла.

4.3. Әлеге карар белән расланган Нигезләмә нигезендә башкарыла торган чыгымнарны финанслау, өстәмә алынган керемнәр булганда, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты исәбеннән гамәлгә ашырыла.

## 5. Җиңүчеләрне билгеләү

5.1. Җиңүчеләр әлеге карар белән расланган комиссия тарафыннан билгеләнә.
5.2. Конкурс таләпләренә һәм шартларына туры килә торган катнашучылар бәяләү кәгазьләре нигезендә әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында билгеләнгән критерийлар нигезендә 5 баллы шкала буенча конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләнәләр. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә.
5.3. Конкурста иң күп тавыш җыйган катнашучы җиңүче дип санала.

## 6. Комиссиянең эш тәртибе

6.1. Комиссия белән комиссия рәисе җитәкчелек итә, ә ул булмаганда-комиссия рәисе урынбасары.

6.2. Комиссия рәисе:

1) комиссия эшенә гомуми җитәкчелек итә һәм әлеге Нигезләмәнең үтәлешен тәэмин итә;

2) конкурс комиссиясе утырышларын үткәрә;

3) Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә башка

гамәлләр башкара.

6.3. Комиссия рәисе урынбасары:

1) комиссия рәисе булмаганда комиссия рәисе вәкаләтләре комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

6.4. Комиссия әгъзалары:

1) комиссия эшендә катнашалар, килгән гаризаларны һәм документларны өйрәнәләр, алар буенча үзләренең кисәтүләрен, тәкъдимнәрен, каршы килүләрен әзерлиләр;

2) комиссия утырышларында катнашалар.

6.5. Комиссия секретаре:

1) комиссия утырышларын үткәрүне оештыра;

2) утырышның көн тәртибе, аны үткәрү датасы һәм урыны турында комиссия әгъзаларына утырышка кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итә;

3) комиссиянең эш кәгазьләрен алып бара.

6.6. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язма рәвештә белдерергә һәм комиссия карарына кушымта итеп бирергә хокуклы.

6.7. Комиссия утырышы комиссия әгъзаларының кимендә өчтән икесе булганда тулы хокуклы дип санала.

Конкурс турындагы
Нигезләмәгә
1 нче кушымта

«Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ
җыелышы беркетмәсеннән өземтә

«___»_______, 20__ ел

Тыңладылар: …
«Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре», «Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» конкурсына кандидатуралар күрсәтү турында».
Баш табиб А.Н. Гайфуллин рәислегендәге конкурс комиссиясе номинациядә медицина хезмәткәрләренең бирелгән документларын карады:

Ф.И.А.
1.______________________________________________________________
2.______________________________________________________________
3.______________________________________________________________
һәм б.ш.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре:
1.______________________________________________________(Ф.И.А.)
әйе______________ каршы________________ тыелдылар____________
2.
_______________________________________________________(Ф.И.А.)
әйе______________ каршы________________ тыелдылар____________
3.______________________________________________________(Ф.И.А.)
әйе______________ каршы________________ тыелдылар____________
һәм б.ш.

Карар иттеләр: «Иң яхшы табиб» номинациясендә конкурста җиңүче дип санарга
_________________________________________________________________
(Ф.И.А.)
_________________________________________________________________
(вазыйфасы, эш урыны)

Карар иттеләр: «Иң яхшы урта медицина хезмәткәре» номинациясендә конкурста җиңүче дип санарга
_________________________________________________________________
(Ф.И.А.)
_________________________________________________________________
(вазыйфасы, эш урыны)

Карар иттеләр: «Иң яхшы медик булмаган хезмәткәр» номинациясендә конкурста җиңүче дип санарга
_________________________________________________________________
(Ф.И.А.)
_________________________________________________________________
(вазыйфасы, эш урыны)

Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының
2025 елның 12 феврале номерлы карарына
2 нче кушымта

**Конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Хәкимуллин Рамил Фатыйхович | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Сабирҗанов Ринат Рәшитович | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Комиссия секретаре: | |
| Фатыйхова Резедә Ильясовна | «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш бухгалтеры |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Гайфуллин Айрат Нурисламович | «Биектау районы үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы |
| Вәлиуллина Рамилә Шамилевна | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Сабирова Гүзәл Фәритовна | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе |
| Минаева Гүзәл Равильевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Биектау муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |